**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ**
**И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ**
**РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

№ 1201-п 03.11.2021

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 20 сентябрендәге 1111-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының ведомство бүлекләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 9 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 20 сентябрендәге 1111-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының ведомство бүлекләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның дүртенче абзацында «50, 55, 60, 65, 70 яшь һәм алга таба» сүзләрен «50, 60 яшь һәм аннан соңгы һәр 10 ел саен» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктны төшереп калдырырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков